# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлегенең Тугай авылы торак пунктта 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

**2023 елның 23 ноябре** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлегенең Тугай авылында гражданнар җыены **карар кабул итте**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлегенең Тугай авылы торак пункты территориясендә 2024 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан тыш, 8350 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә булган урам юл челтәрен тоту һәм ремонтлау, шул исәптән бу максатлар өчен инерт, төзелеш материаллары һәм кече архитектура формалары сатып алу, смета документациясен әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- территориянең Тышкы төзекләндерү объектларын төзү һәм ремонтлау (зиратның киртәсен, "Әрә чишмәсе "чишмәсен ), шул исәптән бу максатлар өчен инерт, төзелеш материаллары һәм кече архитектура формаларын сатып алу, смета документларын әзерләү, төзелеш контролен гамәлгә ашыру (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Беларусь тракторын тоту һәм хезмәт күрсәтү (шул исәптән ягулык-майлау материаллары сатып алу, ПЛН-3 плугы сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);
- торак пункт территориясендә агачларны кисү (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны Күгеш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән түбәндәге адреслар буенча: Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1 йорт (администрация бинасы), Тугай авылы, М. Җәлил урамы, 71 йорт (СК бинасы), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә, кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күгеш авыл җирлеге башлыгы
Зеленодольск муниципаль районы А. А. Гатауллин